

Мордовия  Дәvләт Жыелышында Дәvләт Жыелышы рәисе урынбасары Наталья Долматова  катнашында Ижтимагый яшьләр палатасы утырышы уздырылды.
Яшьләр  парламенты рәисе Виктория Богдашкина билгеләп vткәнчә, 2023 елга  беренчел йомгаклар ясалды. Республикада ике закон чыгару инициативасы  гамәлгә ашырыла, Идел буе федераль округынын (ПФО) Яшьләр парламентлары  ассоциациясе белән актив эш алып барыла. Бердәм Россиянен Яшь Гвардиясе,  «Беренче хәрәкәт» нен тобәк бvлекчәләре һәм Россия авыл яшьләре берлеге  белән хезмәттәшлек турында килешvләр тозелгән (Молодой Гвардией Единой  России, региональными отделениями «Движения первых» и Российского союза  сельской молодежи).

Патриотик һәм экологик юнәлешләргә зур игътибар бирелә, шул исәптән  «Хәтер шәме», «Үлемсез автополк», «Хәтер бакчасы», «Онытылган  каберлекләр юк», «Мордовия Респуб-ликасында чиста урманнар», «Чиста  шәһәр» кебек акцияләр аша да.
Волонтерлык һәм хәйрия эшчәнлеге  активлаша.
Гуманитар миссия белән махсус хәрби операция зонасына  сәяхәтләр оештырыла. Донецк һәм Макеевка балалар медицина учреждениеләре  очен гуманитар ярдәм жыюда ярдәм кvрсәтелде.
Утырышта Яшьләр  парламенты делегациясенен Мәскәvдә «Россия» Халыкара кvргәзмә-форумына  һәм «Боек Ватан сугышы тарихы буенча тест» халыкара акциясенә баруы  турында жентекләбрәк сvз алып барылды. Россия Конституциясенен 30 еллыгына багышланган чараларга басым ясалды.
2023 елда эшнен сонгы  нәтижәләре социаль сәясәт комитеты утырышында тәкъдим ителәчәк. Анын  житәкчесе - Мордовия Дәvләт Жыены рәисе урынбасары Наталья Долматова  яшьләр активынын унай карашын билгеләп vтте.
- Яшьләр парламенты эш  стилен vзгәртте, моһим идеяләрне алга сорv очен мәйданчык булды. Без  уртак эшчәнлегебезне vстерергә тиеш, - диде Наталья Долматова.
Утырышта Ижтимагый яшьләр палатасы һәм анын комиссияләре составында vзгәрешләр расланды. 2024 елга эш планы кабул ителде.
Наилә НАСЫРОВА